Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы
Колай авыл җирлеге башкарма комитеты

# КАРАР

2019 елның 30 апреле № 12

Татарстан Республикасы Питрәч
муниципаль районы Колай
авыл җирлегендә җирләү буенча
хезмәтләрнең гарантияле исемлеге
нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләр
кыйммәтен раслау турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы, «Җирләү һәм җирләү эше турында» 1996 елның 12 гыйнварындагы 8-ФЗ номерлы Федераль законнар нигезендә, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, «Татарстан Республикасында җирләү һәм җирләү эше турында» Федераль законны гамәлгә ашыру чаралары турында» 2007 елның 18 маендагы 196 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары, «2019 елда түләүләрне, пособиеләрне һәм компенсацияләрне индексацияләү күләмен раслау турында» Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2019 елның 24 гыйнварындагы 32 номерлы карары белән Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Колай авыл җирлеге башкарма комитеты карар бирә:

1. Питрәч муниципаль районының Колай авыл җирлегендә 1 нче һәм 2 нче кушымта нигезендә җирләү буенча күрсәтелә торган хезмәтләрнең гарантияле исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләр бәясен 5946,47 сум дип билгеләргә һәм гамәлгә кертергә.
2. Әлеге карарны мәгълүмат стендларында һәм Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районының рәсми сайтында, Колай авыл җирлеге бүлегендә урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә.
3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

Питрәч муниципаль районы
Колай авыл җирлеге
башкарма комитеты җитәкчесе Н.В. Поповская

ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ КУЛАЕВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ИНН 1633605809

Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Колай авыл җирлеге башкарма комитеты карарына 1 нче кушымта

30.04.2019 ел, № 12

Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Колай авыл җирлегендә җирләү буенча гарантияләнгән хезмәтләр исемлеге бәясе

| **Хезмәт күрсәтү исеме** | **Хезмәт күрсәтү бәясе *(сумнарда)*** |
|---|---|
| 1. Җирләү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү | - |
| 2. Җирләү өчен кирәк-яраклар, кирәкле документларны рәсмиләштерү | 1667,76 |
| 3. Үлгән кешенең мәетен (җәсәдләрен) зиратка алып кайту | 384,87 |
| 4. Кабер казырга һәм күмүгә | 3893,84 |
| **Всего** | **5946,47** |

Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Колай авыл җирлеге башкарма комитеты карарына 2 нче кушымта
30.04.2019 ел, № 12

Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Колай авыл җирлегендә җирләү буенча гарантияләнгән хезмәтләр исемлеге бәясе

| **Хезмәт күрсәтү исеме** | **Хезмәт күрсәтү бәясе** ***(суммаларда)*** |
|---|---|
| 1. Җирләү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү | - |
| 2. Тәнне кайтару (облачение тела) | 310,03 |
| 3. Табутны кайтару һәм күмү өчен кирәкле башка предметлар өчен | 1357,73 |
| 4. Үлгән кешенең мәетен (җәсәдләрен) зиратка алып кайту | 384,87 |
| 5. Кабер казу һәм күмү | 3893,84 |
| **Всего** | **5946,47** |